| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ НЫРЬИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>НЫРЬЯ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ** |

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Нырья авылы

**21 июль , 2025 ел** **№ 2**

**Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Балды-Кеня авылында «Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Балды-Кеня авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 09 декабрендәге 1 номерлы Балды-Кеня авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 14 октябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Сез Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Балды-Кеня авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2024 елның 09 декабрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы:
«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге Балды-Кеня авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аталардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1200 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Балды-Кенә авылының Гагарин урамында юлларны рәтләү, ремонтлау һәм вак таш җәеп төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, салу, суүткәргеч торбалар урнаштыру, эш өчен шартнамә буенча түләү, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Балды-Кеня авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре);

- коеларны ясау, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (коеларны ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, эш өчен шартнамә буенча түләү, коеларны төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, спорт һәм уен мәйданчыклары, халыкның башка күпләп ял итү урыннарын, авыл клубы, аның янәшәсен карап тоту, төзекләндерү, ремонтлау), проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, эш өчен шартнамә буенча түләү, Гырон Быдтон паркы территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны карап тоту, яктырткычлар һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

2024 елның 09 декабрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен өстәү өлешендә түбәндәге эшләрне:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Балды-Кеня авылында янгын гидрантларын, янгын сүндерү рукавларын, стволларны, күчермәләрне, колонкаларны, будканы карап тоту, ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка эш төрләре).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 108 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 56 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 56 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Балды-Кеняавылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге Балды-Кеня авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аталардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1200 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Балды-Кеня авылының Гагарин урамындагы юлны төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту, вак таш җәю; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- янгын сүндерү сулыкларын төзү, ремонтлау; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- урам яктыртуны көйләү, ремонтлау, карап тоту; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Балды-Кеня авылының урам юл челтәрен карап тоту

2024 елның 09 декабрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен өстәү өлешендә түбәндәге эшләрне:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Балды-Кеня авылында янгын гидрантларын, янгын сүндерү рукавларын, стволларны, күчермәләрне, колонкаларны, будканы карап тоту, ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка эш төрләре).

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

ОГРН 1021607753111
ИНН 1623002336

Нырья авыл җирлеге башлыгы В.И. Павлов